Минзәлә муниципаль районының
Иске Матвеевка авыл җирлеге Башкарма комитеты
Карары

от « 27 » март 2020 ел. № 6

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының
Иске Матвеевка авыл җирлеге гражданнарыннан үзара салым акчаларын җыю Тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында"гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасының "Җирле референдум турында"гы 23-ЗРТ номерлы Законы, Минзәлә муниципаль районы Иске Матвеевка авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Иске Матвеевка авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Иске Матвеевка авыл җирлеге гражданнарыннан үзара салым акчаларын җыю Тәртибен расларга.

2. Әлеге карар рәсми төстә басылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә йөклим.

Авыл җирлеге башлыгы Нуриев А.Х.

ТР Минзәлә муниципаль районы
Иске Матвеевка авыл җирлеге
Башкарма комитеты
Карарына 1 нче кушымта
дата 27 март 2020 ел. N 6

ТР Минзәлә муниципаль районы Иске Матвеевка авыл җирлеге гражданнарыннан үзара салым акчаларын җыю Тәртибе

1. Әлеге Тәртип авыл җирлеге гражданнарыннан үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарга үзара салым акчаларын түләтү Бөек Ватан сугышында катнашучылардан һәм инвалидлардан, шулай ук 1 төркем инвалидлардан тыш, 18 яше тулган, Минзәлә муниципаль районының Иске Матвеевка авыл җирлеге территориясендә теркәлгән гражданнар тарафыннан, аларның җирле референдумда (гражданнар җыенында) катнашуына һәм тавыш бирүдә белдерелгән мөнәсәбәтенә бәйсез рәвештә, 31 мартка кадәр срокта башкарыла.

3. Аерым категорияле гражданнар өчен:

- Бөек Ватан сугышы ветераннары;
- Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары,
- 1 төркем инвалидлары;
- көндезге бүлектә белем алучы студентлар;
- Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләр.

Җитди сәбәпләр булганда, аларга түбәндәгеләр керергә мөмкин:

а) авыру;

б) озакка сузылган командировка;

өч айдан артмаган срокка гариза нигезендә гражданнарга түләү кертү кичектерелергә мөмкин.

4. Бер тапкыр түләү турында хәбәр язуы (уведомление) бланкы Җирлекнен мәгълүмати стендында, Минзәлә муниципаль районы Иске Матвеевка авыл җирлегенең menselinsk.tatarstan.ru рәсми сайтында бастыру, шулай ук имза куйдырып тапшыру яки почта элемтәсе аша җибәрү юлы белән гражданнарга җиткерелә.

5. Хәбәр язуында (уведомление) гражданнарның үзара салым акчаларын кертүгә түләү реквизитлары, тулысынча яки киметелгән күләмдә бер тапкыр түләү күләме, аны түләү срогы күрсәтелергә тиеш (Кушымта).

6. Гражданнарның үзара салымнан кергән акчалата чаралары Минзәлә муниципаль районы Иске Матвеевка авыл җирлегенең лицевой счетына керә.

7. Гражданнардан түләү алу почта (хисап оешмалары) переводларын башкаруга физик затларның йөкләмәсе буенча исәп-хисап ясауга хокукы булган оешмалар, Минзәлә муниципаль районы Иске Матвеевка авыл җирлеге Башкарма комитеты кассасы, https://uslugi.tatarstan.ru/ сылтамасы буенча Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша акчаларны күчерү юлы белән башкарыла.

8. Касса ордеры квитанциясе, чек-ордер, түләү фактын раслаучы башка документлар түләү фактын раслаучы булып тора.

9. Билгеләнгән срокта гражданнардан алынмаган үзара салым акчалары законда билгеләнгән тәртиптә түләтелә.

2 нче кушымта

ХӘБӘР ЯЗУЫ (УВЕДОМЛЕНИЕ) N ______________ Минзәлә муниципаль районы Иске Матвеевка авыл җирлеге бюджетына үзара салым буенча бер тапкыр түләү кертү турында

түләүченең Ф.Ис.Ат.ис. ______________________________

Адресы: ______________________________

нигезендә

______________________________

Сезгә ____________ срокка кадәр ______________________ чараларны гамәлгә

______________________________ ашыруга бер тапкыр түләү кертергә кирәк.

суммада _______________ сум, түбәндәге реквизитлар буенча: ______________

Түләү алучы банкның БИК ______________________________
Сч. N ______________________________
Кабул итүче Сч. N ______________________________
КПП ______________________________
КБК ______________ ОКАТО ______________
Түләү билгеләнеше ______________________________
Җитәкче ______________________________
М.У. (имза) (тулысынча имза)

- - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - кисү сызыгы - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - - -

Хәбәр язуы (Уведомление) N ________________
Үзара салым буенча бюджетка бер тапкыр түләү кертү турында ______________
______________________________
(муниципаль берәмлек атамасы)
суммада ________________ сум.

түләүченең Ф.Ис.Ат.ис. ______________________________
Адресы: ______________________________
Алдым "___" ______________ 20___ ел. ______________________________

______________________
(түләүченең имзасы)

Искәрмә. Хәбәр язуы төпсәсе (корешок) тутырыла һәм хәбәр язуы түләүченең шәхсән үзенә тапшырылган очракта, Башкарма комитетта кала.